| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **с. Тюлячи** | **КАРАР** |
|---|---|---|
| **«3» мая 2024г.** | | **№ 56** |

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының 2019 елның 22 апрелендәге 263 номерлы «Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре аларга кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 29 апрелендәге 287 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмен арттыру турында һәм «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакына социаль гарантияләр һәм түләүне тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының 2019 елның 22 апрелендәге 263 номерлы «Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре аларга кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карарына (12.10.2020 № 439, 02.03.2022 № 30, 29.09.2022 № 185, 25.10.2022 № 215 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктының өченче абзацын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«- аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакы күләме Теләче муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм

тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе сәркатибенең вазыйфаи хезмәт хакы күләменә тапкырлап исәпләнә, ул 13323 сум тәшкил итә;».

1.2. Карарның 3 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«3) Вазыйфаи окладның 37 проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү.».

1.3. Карарның 7 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«4) Айлык акчалата бүләкләүне - вазыйфаи окладларның 37 проценты күләмендә.».

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасы рәисе Р.Р. Яхинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин